СОВЕТ ТОЙГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ

К А Р А Р

2022 елның 5 декабре

№ 2

2023 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге 45_РТ номерлы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлегенең гражданнар җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге уку формасы студентларыннан, Россия Федерациясе Хәрби көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә 2023 елда үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- МТЗ 320 тракторы өчен кар чистарткыч сатып алу;
- янгын гидрантларын сатып алу;
- янгын гидрантларын урнаштыру өчен бетон боҗралар һәм люклар сатып алу;
- боҗралар һәм янгын гидрантлары урнаштыру өчен монтаж эшләре;
- 10 данә урам яктырткычларын сатып алу һәм алыштыру.;
- узган еллардагы калдыкларны янгын гидрантлары урнаштыруга җибәрергә кирәк.

3. Әлеге карарны Тойгуҗа авылының мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru « Тойгуҗа авыл җирлеге» бүлегендә, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. урнаштырырга

ТР Менделеевск муниципаль районы
Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы Р.А.Сафин